**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ СТАРОМАЗИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**МЕНЗЕЛИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ИСКЕ МАҖЫН**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**17.11. 2019 ел.** **№1**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын авыл җирлеге составына кергән Иске Мажын торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

## КАРАР

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: "2020 елда Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын авыл җирлегенең Иске Мажын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (1 төркем инвалидлардан, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан һәм ветераннардан, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?"

**-зиратка койма тоту;**
**-зират территориясендә хуҗалык блогын төзү.**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 241 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 129 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" позициясе өчен 129 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
"Юк" позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

1. Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын авыл җирлегенең Иске Мажын торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип таныргa.

2. “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын авыл җирлегенең Иске Мажын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (1 төркем инвалидлардан, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан һәм ветераннардан, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны таныргa:

**-зиратка койма тоту;**
**-зират территориясендә хуҗалык блогын төзү.**

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Мажын авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____________ Шаймарданов Э.Р.
(имза) (тулысынча имза)

Иске Мажын авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: ____________ Шаймарданов Э.Р.
(имза) (тулысынча имза)